| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**23.10.2018** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2156** |

Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2011 елның 28 мартындагы 437 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге 1552 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны - муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә

документлар кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләргә консультация бирү тәрәзәсе;  техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, бу белешмәләрне кертүгә нигез булып торган документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 нче пункт).

Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта)»;

1.2. 2.4 пункт «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктату каралмаган» дип өстәргә;

1.3. 2.5 пункты «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында 11) пунктча өстәргә: «Хосусыйлаштыруда катнашудан баш тарту турында (әгәр гаилә әгъзалары хосусыйлаштыруда катнашырга теләмәсә) нотараль расланган гариза» дигән текстка абзац өстәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Департаментта шәхсән мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшыра (җибәрә) ала:

шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат); почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин;

1.4. 2.13 пункт «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң икенче көнне теркәлә.

»дигән абзац өстәргә;

1.5. 3.6.3 пунктыннан соң түбәндәге текст белән 3.7 пункт өстәргә:

«3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәге документларны тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза;

мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ; техник хата булуын дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге аша тапшырыла.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны һәм аңа беркетеп бирелгән документларны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза;

3.7.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатларында, Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып, имза куйдырып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтмәләр кертелгән документны тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына, мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган документның төп нөсхәсен Бүлеккә тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта кулланып) хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыклангханнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (юнәлтелгән) документ».

1.6. 5.1 пунктындагы 2 ) пунктчаны түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү мөмкин, әгәр күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса»; 5 пунктчаны түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү мөмкин, әгәр күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) тиешле

дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса»; 7) пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү мөмкин, әгәр күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса»;

Түбәндәге текстлар белән яңа 8) һәм 9) пунктчаларны кертергә:

8) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү мөмкин, әгәр күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С.Анисимовка әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет Җитәкчесе Д.А. Сапожников